КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 23 май г.Казань № 432

Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыру турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнарга социаль ярдәм күрсәтү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 15 апрель, 296 нчы карарын, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карарын тормышка ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыру турындагы тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасы турындагы нигезләмәне (алга таба – Нигезләмә);

2019 елда социаль хезмәт күрсәтүгә мохтаҗ дип танылган өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыруга юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыруны финанслар белән тәэмин итү кагыйдәләрен.

3. Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына һәм Татарстан Республикасының Сәламәтлек саклау министрлыгына түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

бу карарны тормышка ашыру максатларында ведомство актларын кабул итүне;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 23 декабрь, 1023 нче карары белән расланган 2014 – 2021 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм күрсәтү» дәүләт программасының 2014 – 2021 елларга «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүне модернизацияләү һәм үстерү» ярдәмче программасына теркәлгән 5 нче кушымтада бирелгән Татарстан Республикасында өлкән яшьтәге гражданнарны һәм инвалидларны озак вакыт карау системасын оештыру буенча пилот проектын тормышка ашыруның чаралар планын («юл картасы»н) гамәлгә ашыруны яраштыру, мониторинглау һәм тикшерүдә тоту өчен ведомствоара эшче төркем төзүне.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин